МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

13.04.2018 **г.Казань** № 925-р

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

1. Тәкъдим ителгән Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 25.12.2015 № 3332-р карарын (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 19.01.2016 теркәлгән, регистрация номеры 3171) көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Галиев Артур Ирек улына йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
13.04.2018 № 925-р
карары белән расланды

**Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент федераль милектәге җир кишәрлекләренә кермәгән җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: юридик яки физик затлар, хосусый эшмәкәрләр.

Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бирүчеләр булып дәүләт хезмәтен алучылар яисә һәм дәүләт хезмәтен алучының тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче вәкаләтле вәкиле санала (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр тарафыннан күрсәтелә:

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) - җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү турында үтенеч язуын карау буенча (алга таба – үтенеч язуы), җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында яисә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба – ТР МК) - җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында карар кабул итү яисә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерүдән баш тарту турында карар кабул итү.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр. Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр.

Җәмәгать транспортында:

№ 1, 4, 25, 43, 71 номерлы автобуслар белән "Калинин" тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – «Сукно бистәсе».

1.3.2. Министрлыкның Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлегенең белешмә телефоннары (алга таба - Бүлек): 221-40-36, 221-40-37, 1-49 (эчке), 1-50 (эчке).

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү өчен билгеләнгән бүлмәләренә урнаштырылган дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган мәгълүмат стендларыннан;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – рәсми сайт) (http://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.tatar.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

Мәгълүмати стендлардагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына һәм Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2001, № 44, 4147 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2005, № 1 (1 өлеш), 16 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында” 2001 елның 25 октябрендәге № 137-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 137-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2001, № 44, 4148 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында» 2004 елның 21 декабреннән 172-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон № 172-ФЗ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2004, № 52, 5276 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерация Шәһәр төзү кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2006 елның 18 декабреннән 232-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 52, 5498 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Кадастр эшчәнлеге турында” 2007 елның 24 июлендәге № 221-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2007, № 31, 4017 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 27 июль 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010 ел, № 31, 4179 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль закон (алга таба – Федераль закон № 218-ФЗ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2015, № 29, 4344 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 07 май 2012, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президенты Указы № 601) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 19, 2338 б.);

Татарстан Республикасы Җир кодексы (алга таба – ТР ҖК) (Татарстан Республикасы, 1998, 15 август, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.12.2005 № 563 карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең

республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 47-48, 0985 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү турында үтенеч формасын һәм аңа беркетелә торган документлар составын раслау» 25.10.2006 № 523 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – ТР МК карары № 523) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2006, № 41-42, ст. 1061, с учетом внесенных изменений);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре" 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2007, №37, 1379 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында" 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 675 ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2011, № 39, 1928 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе турында" 07.08.2012, № 674, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара

бәйләнеше тәртибе («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 59, 2041 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

күпфункцияле үзәкнең дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – муниципаль районнардагы авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе;

техник хата – документларга кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) дөреслеккә туры килмәвенә китерүче Министрлык хатасы (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата);

җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында үтенеч язуы (алга таба – үтенеч язуы) - 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау. Үтенеч язуының формасы ТР МКның № 523 карары белән расланган һәм әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү | РФ ЖК; ТР ЖК;<br>Федераль закон № 172-ФЗ;<br>Федераль закон № 221-ФЗ;<br>ТР МК карары № 523;<br>Нигезләмә |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Министрлык - үтенеч язуын карау буенча, җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында яисә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләү;<br>ТР МК - җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында карар кабул итү яисә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән | Нигезләмә 3.3.26 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | башка категориягә күчерүдән баш тарту турында карар кабул итү | |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында яисә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерүдән баш тарту турында ТР МК карары.<br>Үтенеч язуын һәм аңа беркетелгән документларны караудан баш тарту турында хат | РФ ҖК 8 ст; ТР ҖК 8 ст.;<br>Федераль закон № 172-ФЗ;<br>ТР МК карары № 523 |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучыларның оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату срогы | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте үтенеч язуы һәм документлар Министрлыкка кергән көннән башлап 44 эш көне эчендә күрсәтелә. Моңа түбәндәгеләр керә:<br>22 көн вакыт эчендә Министрлык үтенеч язуын карый һәм Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында яисә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерүдән баш тарту турында ТР МК карары, | Федераль закон № 172-ФЗ;<br>ТР МК карары № 523 |

| | | |
|---|---|---|
| | яки үтенеч язуын һәм аңа беркетелгән документларны караудан баш тарту турында хат әзерли.<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламентына туры китереп, Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында яисә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерүдән баш тарту турында ТР МК карары кабул ителә. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе, шул исәптән электрон формада; аларны тапшыру тәртибе. | Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү өчен гариза бирүче Министрлыкка Үтенеч язуы тапшыра. Үтенеч язуының формасы ТР МК № 523 карары белән расланган (1 нче кушымта).<br>Үтенеч язуына түбәндәгеләр теркәлә (һәрберсе 1 данә):<br>1) дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе (аның үткәрелүе федераль законнарда каралган очракта);<br>2) җир кишәрлегенә хокук иясенең җир кишәрлеген бер категория җир составыннан | Федераль закон № 172-ФЗ;<br>ТР МК карары № 523 |

| | | |
|---|---|---|
| | башка категориягә күчерергә ризалыгы; әлеге җир кишәрлегенә сервитут урнаштыру турында килешү төзелгән зат җиргә хокук иясе булып торган очраклар искәрмә булып тора.<br>Дәүләт һәм муниципаль милектә, әлеге җир кишәрлеге белән эш итү вәкаләте булган җирле үзидарә органында булганда, җир кишәрелеген күчерү турында ризалык карар формачында тапшырыла;<br>3) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге соралган җирләрнең чикләре, торак пунктларның чикләре һәм атамалары, кырларның төрләре, гидрография элементлары чикләре һәм автомобиль юллары билгеләнгән 1:25000 яки 1:10000 масштабындагы план-картография материалы;<br>4) ышанычнамә (Үтенеч язуын гариза бирүченең вәкиле имзалаган очракта);<br>5) җирле үзидарә вәкаләтле органының җир кишәрлеген бирү турында беренчел килешүе турында карары (җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән РФ ҖК 39.15 статьясы 1 пункты 6 подпункты нигезендә бирелгән очракта, җир кишәрлеген | |

| | | |
|---|---|---|
| | ясау ихтыяҗы булганда яисә чикләрен төгәлрәк билгеләргә кирәк булганда), җир кишәрлеген ясарга кирәк булганда һәм чикләрендә әлеге җир кишәрлеген ясарга кирәк булган территориянең ызанлау проекты булмаганда, аңа җир кишәрлегенең кәгазьгә ясалган урнашу схемасын теркәлә;<br>6) җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе күчермәсе (килешү булган һәм Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрында чикләнгән хокуклар һәм аның аренда рәвешендә комачаулыгы булуы турында белешмә булмаган очракта);<br>7) җир кишәрлеген файдалы казылмалар табыштыру белән бәйле рәвештә күчергәндә – үтенеч язуына түбәндәгеләр теркәлә:<br>нотариаль яисә җитәкче яки аның вәкаләтле вазыйфаи заты имзасы белән һәм җир асты байлыкларын файдаланучы оешманың мөһере (Россия Федерациясе законнары мөһер булдыру мәҗбүрилеген билгеләгән очракта) белән таныкланган түбәндәге күчермәләр:<br>җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия;<br>лицензиягә (булган очракта) өстәмә | |

| | | |
|---|---|---|
| | килешү (өстәмәләр);<br>җир асты файдаланыласы урынның чикләре план-картография материалында билгеләнгән горноотвод акты (таяну, параметрик, структуралы, эзләнүле, бияләү һәм тикшеренү скважиналарын урнаштырудан башка);<br>8) җир асты байлыкларын чыгару белән бәйле очракларда тиешле тәртиптә расланган җирләрне рекультивацияләү проекты, яки линияле объектлар төзелеше вакытында бирелә торган авыл хуҗалыгы җирләре өлешен рекультивацияләү проекты;<br>9) җир кишәрлеген гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары янындагы полосалар чигеннән күчергән очракта – килешүләр:<br>Россия Федерациясе законнары нигезендә хокукый яктан автомобиль юлларын биләп торган дәүләт хакимияте, җирле администрациянең башкарма органы (муниципаль берәмлекнең башкарма – оештыру органы), физик яки юридик затлар;<br>«Юл хәрәкәте иминлеге» ресмпублика дәүләт учреждениесе (җир кишәрлеге Татарстан Республикасының гомуми | |

| | | |
|---|---|---|
| | кулланылыштагы автомобиль юллары янындагы полосада урнашкан очракта).<br>10) Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге категориядән башка категориягә күчерү килештерүләре:<br>Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;<br>Идел буе федераль округының Җир асты казылмаларын файдалану департаментының Татарстан Республикасы буенча Геология һәм лицензияләр бирү бүлеге (җир асты байлыкларын чыгару белән бәйле очраклар искәрмә булып тора);<br>Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы;<br>Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы;<br>Муниципаль берәмлекнең башкарма-оештыру органы – җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә соралган җир кишәрлегендә расланган территорияне планлаштыру документы нигезендә федераль объектлар (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 10 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән өлкәләрдә), җирле әһәмияткә ия объектлар, республика | |

| | | |
|---|---|---|
| | әһәмиятендәге объектлар урнаштыру өчен күчергән очракта. Килештерү шартлы билгеләр, соралган җир кишәрлеге чикләре күрсәтелгән тиешле дәрәҗәдә эшләнгән территориаль планлаштыру документыннан күчермәгә вәкаләтле вазыйфаи зат имзасы куелган кушымта белән тапшырыла.<br>Физик затлар, шул исәптән юридик затларның вәкилләре һәм индивидуаль эшмәкәрләр гариза бирүченең шәхесен раслаган документларының күчермәләрен һәм персональ документларны эшкәртүгә ризалык бирәләр.<br>Үтенеч язуына теркәлгән документлар (7 подпунктта күрсәтелгәннәр искәрмә булып тора) нотариуста яки документның төп нөсхәсен биргән орган (оешма, учреждение) тарафыннан таныкланмаган булса, күчермәләре тапшырылган төп нөсхә күрсәтелә һәм Министрлык белгече тарафыннан таныклана.<br>Дәүләт хезмәтен алу өчен үтенеч язуы бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхсән үзе мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Үтенеч язуы һәм аңа беркетелгән документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьгә бастырылып түбәндәге ысуллар белән тапшырыла (җибәрелә) ала:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче тарафыннан);<br>почта аша. | |
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда саклanган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар саклanган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРЮЛ) гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә, яки Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча ФСХИ) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрының язу бите.<br>2. Шәхси эшмәкәрләр бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРИП) гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында өземтә яки ТР буенча Федераль салым идарәсеннән шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан язу бите.<br>3. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба | Федераль закон № 172-ФЗ;<br>ТР МК карары № 523. |

| | | |
|---|---|---|
| | – ФКП РТ) җир кишәрлеге турында яки ЕГРНда җир кишәрлеге турында соралган мәгълүматлар блумавы турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (алга таба – ЕГРН).<br>Гариза бирүчеләр өстә күрсәтелгән документларны түбәндәге очракларда мөстәкыйль рәвештә үзләре китерә ала:<br>Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә яки Юридик затларның бердәм дәүләт реестрының язу битен үтенеч язуын тапшырганчы бер айдан да күбрәк булмаган вакытта Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына;<br>Күчемсез милек дәүләт бердәм реестрыннан җир кишәрлеге турында өземтә үтенеч язуын тапшырганчы 6 айдан күбрәк булмаган вакытта Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән.<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнары һәм башка дәүләт оешмаларында булган документларны таләп итү тыела.<br>Өстә күрсәтелгән документларны тапшырмау дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түбәндәге килештерхләр таләп ителә:<br>Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;<br>Идел буе федераль округының Җир асты казылмаларын файдалану департаментының Татарстан Республикасы буенча Геология һәм лицензияләр бирү бүлеге (җир асты байлыкларын чыгару белән бәйле очраклар искәрмә булып тора);<br>Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы;<br>Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы;<br>Муниципаль берәмлекнең башкарма-оештыру органы – җир кишәрлеген бер | ТР МК карары № 523 |

| | | |
|---|---|---|
| | категориядән икенче категориягә соралган җир кишәрлегендә расланган территорияне планлаштыру документы нигезендә федераль объектлар (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 10 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән өлкәләрдә), җирле әһәмияткә ия объектлар, республика әһәмиятендәге объектлар урнаштыру өчен күчергән очракта. Килештерү шартлы билгеләр, соралган җир кишәрлеге чикләре күрсәтелгән тиешле дәрәҗәдә эшләнгән территориаль планлаштыру документыннан күчермәгә вәкаләтле вазыйфаи зат имзасы куелган кушымта белән тапшырыла. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Законнарда дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Үтенеч язуын караудан баш тарту өчен нигезләр:<br>1. Үтенеч язуы белән тиеш булмаган затның мөрәҗәгать итүе.<br>2. Үтенеч язуына теркәлгән документларның составы, формасы яки | РФ ЖК;<br>Федераль закон № 172-ФЗ, 3, 4 ст.<br>ТР МК карары № 523 |

| | | |
|---|---|---|
| | эчтәлеге җир законнары таләпләренә туры килми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен (күчерүдән баш тарту) нигезләр:<br>1. Федераль законнар нигезендә җирләрне яисә әлеге җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерүдә чикләүләр куелган булуы яки мондый күчерүләрнең тыелуы.<br>2. Дәүләт экологик экспертизасының тискәре бәяләмәсе булганда (аны үткәрү федераль законнарда каралган очракларда).<br>3. Соралган җирләрнең яки җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше территорияне планлаштыруның расланган документларына һәм территорияне планлаштыру документациясенә, җир төзелеше документациясенә туры килмәве билгеләнгәндә. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен | Зарури һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү түләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br><br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президенты Указы № 601, 1 п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын рәсмиләштерү срогы, шул исәптән электрон формада | Үтенеч язуы һәм документлар кергән бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә рәсмиләштерелә.<br>Документлар төп нөсхәдә тапшырыла. Хезмәт электрон формада күрсәтелми. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтеп тору һәм кабул ителү урыннарына, шул исәптән, Россия Федерациясенең | Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы урнаштырылган, документлар тутыру өчен кирәкле җиһазы һәм мәгълүмати стенд куелган бүлмәләрдә башкарыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| инвалидларны социаль яклау турында законнарына туры китереп әлеге объектларның инвалидлар керә алырлык булуын тәэмин итүгә карата, хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиалы мәгълүматка таләпләр | Инвалидларга каршылыксыз керә алу, шул исәптән каршылыксыз кереп чыгу мөмкинлеге белән тәэмин ителә, шул исәптән тиешле урынга килеп җитә алу максатында объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тудырыла.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текст форматында һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән, инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуы да күздә тотыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән, гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше саны һәм аның вакыт буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрнең ераклаштырылган эш | Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:рас Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;<br>кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br><br>Министрлык бинасын һәм бүлмәләрне инвалидларга дәүләт хезмәте күрәстелгән бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыра торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү; | |

| | | |
|---|---|---|
| урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып | инвалидлар өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыру белән бәйле булмаган, башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтелергә комачаулаган башка барьерларны үтәргә булышу;<br><br>кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br><br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүматның булуы.<br><br>Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br><br>документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br><br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;<br><br>Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозулары турында нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br><br>Гариза бирүченең министрлык белгечләре | |

| | | |
|---|---|---|
| | белән үзара бәйләнеш саны:<br><br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә ике тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артмый;<br><br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел.<br><br>дәүләт хезмәте күрсәткәндә белгеч белән гариза бирүченең бәйләнеш вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br><br>Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә, күп функцияләр башкаручы үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыннарында күрсәтелми.<br><br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматны Министрлыкка телдән (шәхсән үзе яисә телефоннан) яки язмача мөрәҗәгать итеп, шулай ук Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша белешә ала. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтелми. | |

**3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре, шулай ук, административ процедураларның күпфункцияле үзәкләрдә, күп функцияле үзәкләрнең дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча ераклаштырылган эш урыннарында**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

үтенеч язуы һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;

үтенечкә теркәлгән документларның составын, формасын һәм эчтәлеген карау; гариза бирүчегә үтенечне каарудан баш тарту турында хат юллау;

җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында яисә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләү; проектны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллау;

гариза бирүчегә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында яисә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын юллау;

техник хатаны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 3 нче кушымтада китерелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән үзе, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, аның нинди ысул белән мөрәҗәгать итүенә карап, шәхсән үзенә, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән консультация бирә, шул исәптән тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр буенча, гариза бирүчегә ярдәм итә, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча да.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне (гариза теркәлгән көн) үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, гаризи бирүчегә күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тутырырга булышу.

3.3. Үтенеч язуы һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән үтенеч язуын Министрлыкка бирә.

Үтенеч язуы һәм нотариуста яисә төп нөсхәне биргән орган (оешма) тарафыннан расланган документ күчермәләре почта аша да юллана ала.

3.3.2. Эш башкару һәм контроль бүлеге белгече (алга таба – эш башкару бүлеге) Бүлек белгече катнашында үтенеч язуын һәм документларны кабул итеп ала, рәсмиләштерә һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура үтенеч язуы һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлеккә юлланган үтенеч язуы һәм аңа теркәлгән документлар.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау;

3.4.1. Бүлек белгече үтенеч язуын һәм аңа теркәлгән документларны Эш башкару бүлегеннән алгач, “ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү турында үтенеч язуы үтү битен” (2нче кушымта) һәм ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада түбәндәге запросларны юллый:

гариза бирүче булып торган оешма - юридик зат турында белешмә бирү турында, ТР буенча ФСХИдан;

гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында белешмә бирү турынды ТР буенча Федераль салым идарәсеннән;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: белешмәләр (документлар) бирү турындагы запрослар.

3.4.2. Ведомствоара арадашлык органнары белгечләре ведомствоара электрон арадашлык системасы аша кергән 3.4.1 пунктта күрсәтелгән запрослар нигезендә законнарда билгеләнгән тиешле срокларда соралган документларны (белешмәләр) бирәләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булып торган белешмәләр (документлар), яисә, баш тарту турында Министрлыкка юлланган белдерү кәгазе.

3.5. Үтенеч язуына беркетелгән документларның составын, формасын һәм эчтәлеген карау; гариза бирүчегә үтенеч язуын караудан баш тарту турында хат юллау

3.5.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пункты нигезендә юлланган запрослар буенча белешмәләр алганнан соң, үтенеч язуын караудан баш тартырлык әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавы өчен үтенеч язуына беркетелгән документларның составын, формасын һәм эчтәлеген тикшереп чыга.

3.5.2. Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта үтенеч язуын караудан баш тарту турында хат әзерли һәм аның Бүлек мөдире белән, Җир ресурслары идарәсе башлыгы белән, хокук идарәсе башлыгы белән килештерелүен, үтенеч язуын караудан баш тарту турындагы хатка министр урынбасарыннан кул куелуын, Министрлыкта Эш башкару инструкциясендә күрсәтелгән тәртиптә гариза бирүчегә юллануын тәэмин итә.

3.5.1, 3.5.2 пунктлар белән билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.4.1 пункты нигезендә юлланган запросларга җаваплар алынганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: үтенеч язуын караудан баш тарту турында гариза бирүчегә юлланган хат.

3.6. Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында яисә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләү (алга таба – ТР МК карары проекты); ТР МК карары проекты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллау.

3.6.1. Үтенеч язуын караудан баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

Карап чыгу: үтенеч язуын һәм аңа беркетелгән документларны; Министрлык запрослары буенча килгән җавапларны (белешмәләр, документлар);

җирне авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башкага күчерүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын ачыклау;

үтенеч язуын һәм аңа беркетелгән документларны караганнан соң ТР МК карары проектын әзерләү һәм ТР МК карары проектын, аңа кушып җибәрелә торган хат проекты белән бергә, килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллау.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан өч эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган ТР МК карары проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проекты.

3.6.2. Бүлек мөдире ТР МК карары проектын һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проектын карый, проектларны килештерү өчен Җир ресурслары идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдире тарафыннан килештерелгән һәм килештерү өчен Идарә башлыгына юлланган ТР МК карары проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проекты.

3.6.3. Идарә башлыгы ТР МК карары проектын һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проектын карый, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Идарә башлыгы тарафыннан килештерелгән ТР МК карары проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проекты.

3.6.4. Бүлек белгече Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы тарафыннан килештерелгән ТР МК карары проектын һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проектын Министрлыкның хокук идарәсенә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң икенче көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм хокук идарәсенә юлланган ТР МК карары проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проекты.

3.6.5. Хокук идарәсе белгече: ТР МК карары проектына хокукый экспертиза ясый, аңа кушып җибәрелә торган хат проектын карый, килештерә һәм килештерү

өчен хокук идарәсе башлыгына юллый яисә кимчелекләр булган очракта, имзалау өчен - ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсен.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсе яки килештерелгән һәм хокук идарәсе башлыгына юлланган ТР МК карары проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проекты.

3.6.6. Хокук идарәсе башлыгы хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча ТР МК карары проектын һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проектын килештерә яисә ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсенә кул куя һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң икенче көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә юлланган хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән ТР МК карары проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проекты яисә хокук идарәсе башлыгы кул куйган ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсе.

3.6.7. Бүлек белгече ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта кимчелекләрне бетерә һәм ТР МК карары проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проектын килештерү өчен яңадан хокук идарәсе башлыгына юллый.

3.6.8. Хокук идарәсе башлыгы ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрнең бетерелгән булуын тикшерә һәм ТР МК карары проектын һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проектын килештерә.

3.6.7 һәм 3.6.8 пунктларда билгеләнгән процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә юлланган хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән ТР МК карары проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проекты.

3.6.9. Бүлек белгече ТР МК карары проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проектын килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң икенче көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юлланган ТР МК карары проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проекты.

3.6.10. Министрның беренче урынбасары ТР МК карары проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проектын килештерә һәм имза кую өчен министрга юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары тарафыннан килештерелгән һәм имза кую өчен министрга юлланган ТР МК карары проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проекты.

3.6.11. Министр ТР МК карары проектына кушып җибәрелә торган хат проектына кул куя, проектны килештерә һәм регистрация өчен эш башкару бүлегенә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң икенче көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Регистрация өчен эш башкару бүлегенә юлланган имзаланган ТР МК карары проектына кушып җибәрелә торган хат, министр тарафыннан килештерелгән ТР МК карары проекты.

3.6.12. Эш башкару бүлеге белгече ТР МК карары проектын һәм аңа кушып җибәрелә торган хатны рәсмиләштерә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң икенче көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланган ТР МК карары проекты беркетелгән кушып җибәрелә торган хат.

3.7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ТР МК карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карый.

Процедуралар нәтиҗәсе: җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында яисә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба урынына карап – күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында)

3.8. Гариза бирүчегә күчерү турында карарны (күчерүдән баш тарту турында) юллау

Бүлек белгече Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында) килгәч, кушып җибәрелә торган хат әзерли, аның министрның беренче урынбасары тарафыннан имзалануын, эш

башкару бүлегендә регистрация үтүен һәм күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында) күчермәсе белән бергә кушып җибәрелә торган хатның эш башкару бүлеге Инструкциясендә билгеләнгән тәртиптә гариза бирүчегә юллануын тәэмин итә.

Әлеге пункт билгели торган процедура күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында) Министрлыкка килеп кергәннән соң өч эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган хат һәм аңа беркетелгән күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында).

3.9. Дәүләт хезмәте электрон формада, күпфункцияле үзәкләр, күпфункцияле үзәкләрнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыны аша күрсәтелми.

3.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән техник хаталарны төзәтү

3.10.1. Гариза бирүченең күчерү турында карарда киткән техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгате Министрлык тарафыннан техник хатаның төзәтелүенә нигез булып тора.

Техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хаталарны төзәтү турында мөрәҗәгать (4 нче кушымта);

күчерү турында карар;

техник хатаның булуын дәлилләгән документлар.

3.10.2. Күчерү турында карарда техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьне гариза бирүче Министрлыкка шәхсән үзе тапшыра яисә почта аша юллый.

3.10.3. Эш башкару бүлеге белгече мөрәҗәгатьне, беркетелгән документлары белән бергә, кабул итеп ала һәм, теркәп, Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт билгели торган процедура мөрәҗәгать һәм документлар бирелгән (кергән) көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карау өчен Бүлек белгеченә юлланган мөрәҗәгать.

3.10.4. Бүлек белгече документларны карап чыга, җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын (алга таба – үзгәрешләр кертү турында карар проекты) әзерли. Үзгәрешләр кертү турында карар проекты әзерләнгәч процедуралар әлеге Регламентның 3.6.2. 3.6.3, 3.6.9-3.6.12 пунктларында каралган тәртиптә башкарыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хата табылганнан соң яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан хата җибәрелү турында мөрәҗәгать алган көннән соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: әзерләнгән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланган үзгәрешләр кертү турында карар проекты.

3.10.5. Бүлек белгече Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан үзгәрешләр кертү турында карар килгәч, кушып җибәрелә торган хат әзерли, аның министрның беренче урынбасары тарафыннан имзалануын, эш башкару бүлегендә регистрация үтүен һәм үзгәрешләр кертү турында карар белән бергә кушып җибәрелә торган хатның гариза бирүчегә юллануын тәэмин итә.

Әлеге пункт билгели торган процедура үзгәрешләр кертү турында карар Министрлыкка килеп кергәннән соң өч эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган хат һәм аңа беркетелгән үзгәрешләр кертү турында карар.

3.10.6. Техник хатаны төзәтүгә кагылышлы документларны (беркетелгән документлар белән бергә техник хатаны төзәтү турында мөрәҗәгать, үзгәрешләр кертү турында карар проекты, үзгәрешләр кертү турында карар) күчерү турында карар нөсхәсенә беркетелә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчеләре әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны күзәтү юлы белән контрольдә тота.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр куя торган башка норматив хокукый актларның үтәлешен тикшереп тору юлы белән тормышка ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә тормышка ашырыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган

мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәге тикшерүләр тора:

эш башкаруны алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр бирү срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча).

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламент һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр куя торган башка норматив хокукый актлар таләпләренең бозылуы алдарак ачыкланган булып, аларның төзәтелгәнлеген тикшерү өчен кирәк булганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре аркасында гариза бирүчеләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуы турында шикаятьләр булганда.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Министрлыкның карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә, Министрлыкның дәүләт хезмәт күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затыннан яисә дәүләт хезмәткәреннән зарланып Министрлыкка шикаять бирергә хокуклы.

Министрның дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы һәм тәртибе бозылганда;

9) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең туктатылуы федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда күздә тотылмаган булып та, ул туктатылса.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль

хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш::

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, мөрәҗәгать итүче юридик затның урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда күрсәтелгән шартларны раслый торган документлар теркәлә ала. Бу очракта теркәләгән документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаять карап тикшерү вакыты – аны регистрацияләгәннән соң 15 көн. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә

5.8. Министрлык шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.9. Әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Форма
(МКның № 523 карары белән расланган)

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгына

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешеннән
башка категориягә күчерү турында
үтенеч язуы

___________________________________________________________________________

(гражданинның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме яки юридик затның атамасы)

гомуми җир кишәрлеген мәйданы ________________________________________ гектар булган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән

кадастр номеры ____________________________________________________,

_____________________________________________________ хокукында

(хокук атамасы)

__________________________________________________________________________

(җирдән файдаланучының атамасы)

Татарстан Республикасының ___________________________ районы территориясендә

(муниципаль район атамасы)

_______________________________________________________________ категориясенә

(җир кишәрелеген күчерү соралган категория атала)
_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________ күчерүне сорыйм.

(максатчан билгеләнеше)

Күчерү нигезе: территорияне планлаштыруның расланган документына туры килә
_____________________________________________

(муниципаль берәмлек Советының территорияне планлаштыру документынраслау турындагы карар реквизитлары,

___________________________________________________________________________

территорияне планлаштыруның расланган документларына үзгәрешләр кертү турында каарар реквизитлары (булса)

| | | |
|---|---|---|
| Гариза бирүченең почта адресы | | |
| | | |
| Контакт телефоны | | |

Әлеге үтенеч язуына исемлек буенча документлар теркәлә.

Гариза бирүче(ләр)нең, ышанычнамә буенча вәкил(ләр)нең имзасы.

«__» ___________ № ______________.

________________________________________________________/________________________/

(гариза бирүченең (вәкилнең) фамилиясе, исеме, этисе исеме) (имза)

М.П. <*>

--------------------------------

<*> Россия Федерация законнарында мөһергә ия булу мәҗбүри каралган очракларда

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта


## ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү турында үтенеч язуының үтү бите


Үтенеч язуының керү датасы (регистрация) ___________________________________
Гариза бирүче _______________________________________________
Регистрация (керү) номеры _______________________


| N п/п | Министрлык бүлекчәләре | Алу датасы | Имза | Тапшыру датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Эш башкару һәм контроль бүлеге | | | | |
| 2. | Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге белгече | | | | |
| | Килештерүләр: | | | | |
| 3. | Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге мөдире | | | | |
| 4. | Җир ресурслары идарәсе башлыгы | | | | |
| 5. | Хокук идарәсе белгече | | | | |
| 6. | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 7. | Министрның беренче урынбасарының кабул итү бүлмәсе (документларга кул кую) | | | | |
| 8. | Министрның кабул итү бүлмәсе (документларга кул кую) | | | | |
| 9. | Эш башкару һәм контроль бүлеге (документларны формалаштыру һәм регистрация) | | | | |

Җир кишәрлегән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы




Идарә башлыгы
ТР МК карары проектын, кушып җибәрелә торган хат проектын килештерә
Килештерелгән ТР МК карары проекты, кушып җибәрелә торган хат проекты
Бүлек белгече
Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы килештергән ТР МК карары проектын, кушып җибәрелә торган хат проектын хокук идарәсенә юллый
Хокук идарәсенә юлланган ТР МК карары проекты, кушып җибәрелә торган хат проекты
Хокук идарәсе белгече
ТР МК карары проектына хокукый экспертиза ясый, ТР МК карары проектына кушып җибәрелә торган хат проектын карый
ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсе яки килештерелгән ТР МК карары проекты
Хокук идарәсе башлыгы
ТР МК карары проектына хокук идарәсе бәяләмәсен карый яки ТР МК карары проектын һәм кушып җибәрә торган хатны килештерә
Килештерелгән ТР МК карары проекты, кушып җибәрелә торган хат проекты
ТР МК карары проекты буенча бәяләмә
Бүлек белгече
ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта кимчелекләрне бетерә һәм ТР МК карары проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат проектын килештерү өчен яңадан хокук идарәсе башлыгына юллый.
Хокук идарәсенә экспертизага юлланган ТР МК карары проекты, кушып җибәрелә торган хат проекты
Хокук идарәсе башлыгы
ТР МК карары проекты буенча бәяләмәне имзалый яки ТР МК карары проектын, кушып җибәрелә торган хат проектын килештерә
Килештерелгән ТР МК карары проекты, кушып җибәрелә торган хат проекты
Бүлек белгече
ТР МК карары проекты, кушып җибәрелә торган хат проектын килештерү өчен миничтрның беренче урынбасарына юллый
Министрның беренче урынбасарына килештерү өчен юлланган ТР МК карары проекты, кушып җибәрелә торган хат проекты
Министрның беренче урынбасары
ТР МК карары проектын, кушып җибәрелә торган хат проектын килештерә һәм министрга кул куярга юллый
Килештерелгән ТР МК карары проекты, кушып җибәрелә торган хат проекты


Министр
ТР МК карары проектын килештерә, кушып җибәрелә торган хат проектына кул куя
Килештерелгән ТР МК карары проекты белән имзаланган кушып җибәрелә торган хат проекты
Эш башкару бүлеге белгече
ТР МК карары проекты белән кушып җибәрелә торган хатка регистрация ясый һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллый; үтенеч язуын караудан баш тарту турында хатка регистрация ясый һәм гариза бирүчегә юллый
Гариза бирүчегә юлланган үтенеч язуын караудан баш тарту турында хат
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланган ТР МК карары проекты һәм кушып җибәрелә торган хат
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
ТР МК карары проекты
Күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында)
Бүлек белгече
Күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында) күчермәсенә кушып җибәрә торган хат әзерли, аның министрның беренче урынҗасары тарафыннан имзалануын, эш башкару бүлегендә регистрация үтүен һәм Күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында карар) күчермәсе белән гариза бирүчегә юллануын тәэмин итә
Гариза бирүчегә юлланган Күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында) күчермәсе белән хат

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрына

# Техник хатаны төзәтү турында
# гариза

_______________________________________________________________________________
(юридик зат атамасы, физик затның, шәхси эшмәкәрнең Ф.И.О (булса))
____________________________________________________________________ йөзендә,
(Ф.И.О (булса), вәкилнең вазыйфасы)
_____________________________________________________нигезендә эш итеп
(вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ атамасы)
җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә киткән техник хатаны төзәтүне һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «____»_________ 20______ел №________ карарына тиешле үзгәрешләр кертүне сорый.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «____»_________ 20______ел №________карарында язылган:___________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

Дөрес белешмә:_________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.

Гариза бирүче (гариза бирүчеләр) турында белешмә:

| | |
|---|---|
| Юридик зат реквизитлары *(ОГРН, ИНН, адрес (урнашкан урыны)* | |
| | |
| | |
| Физик зат өчен (юридик затның вәкиле) паспорт мәгълүматлары *(серия, номер, кем кайчан биргән, подразделение коды, теркәлү адресы),* Яшәгән адресы (теркәлү адресы белән туры килмәгән очракта), ИНН | |
| Телефон, почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы | |

| Җир кишәрлеге турында белешмә | |
|---|---|
| Кадастр номеры | |
| Җир кишәрлеге урнашкан урын | |

“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү гариза имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Гариза бирүченең имзасы (_______№__________________________ышанычнамә буенча вәкил

_________________________________________/________________________/

(вәкилнең фамилия, имя, этисе исеме (соңгысы – булганда), имзасы)

М.П. (мөһер булганда)

Гариза кабул ителде: "___"_________ 20__ г.

______/__________________/гаризаны алган Бүлек белгеченең имзасы, фамилиясе, инициаллары)

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

**Персональ мәгълүматны эшкәртү өчен рөхсәт**

Мин, ____________________________________________________________
“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. Адресында урнашкан Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү үтенеч язуы имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Гариза бирүченең имзасы (ышанычнамә буенча вәкил ____ №_______________

_____________________________________/_____________________/

(вәкилнең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме (булса) имзасы)

Үтенеч язуы кабул ителде: «___»_________ 20__ ел.
____________/__________________________________________/
имза (гаризаны алган белгечнең фамилиясе, инициаллары)

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

**Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Галиев Артур Ирек улы | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсе башлыгы<br>Миндубаева Гүзәл Эдуард кызы | 221-40-30 | Guzel.Mindubaeva@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге мөдире<br>Мөбәрәков Алмаз Газинур улы | 221-40-36 | almaz.mubarakov@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81<br>221-40-83 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты,
агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе башлыгы<br>Мостафин Айрат Рафинант улы | 264-77-15 | Ayrat.Mustafin@tatar.ru |
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе башлыгы урынбасары<br>Аксанов Валерий Аркадьевич | 264-76-89 | Valeriy.Aksanov@tatar.ru |